КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15.11.2024 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2024 елның 11 нче, 12 нче, 13 нче, 14 нче, 15 нче ноябрь көннәрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Шәмәрдән торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Тротуарларны төзү, ремонтлау (Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән торак пунктында җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән җәяүлеләр тротуарларын оештыру);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (туфрак эшкәртү, комлы нигез салу, юл кырыйларын төзү, су үткәрү торбаларын төзекләндерү, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән торак пунктында шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән торак пунктында спорт мәйданчыгын төзекләндерү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 4372 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 2286 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 2239 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 47 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

1. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Шәмәрдән торак пунктында Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге составына керүче Шәмәрдән торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә” һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Тротуарларны төзү, ремонтлау (Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән торак пунктында җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән җәяүлеләр тротуарларын оештыру);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (туфрак эшкәртү, комлы нигез салу, юл кырыйларын төзү, су үткәрү торбаларын төзекләндерү, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән торак пунктында шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- Торак пункт территориясен төзекләндерү»Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Шәмәрдән торак пунктында спорт мәйданчыгын төзекләндерү).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Шәмәрдән авыл
җирлеге башлыгы

А.К.Валиев